**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3645**
**31.05.2021**

Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон формада, дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр һәм социаль әһәмияткә ия дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә күчү буенча чаралар планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында игезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Күпфатирлы йорттагы бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йорттагы бүлмәләрне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру тәмамлану турында акт рәсмиләштерү»;

- 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Төзелешкә рөхсәт бирү»;

- 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару»;

- 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү»;

- 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Агачларны, куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү»;

- 42 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42. Җир участогыннан яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү»;

- 55 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«55. Җир участогын, сатулар үткәрмичә, түләү нигезендә арендага, милеккә бирү»;

- 58 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«58. Җир участогын сатуларда арендага, милеккә бирү»;

- 63 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«63. Планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү турында белдерү кәгазе җибәрү»;

- 64 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«64. Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазе җибәрү»;

- 74 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«74. Проект документларын, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топографик планны килештерү»;

- түбәндәге эчтәлектә 79 пункт өстәргә:

«79. Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектларының дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов